**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7075**
**28.11.2018**

Яр Чаллы шәһәрендә иң яхшы студентлар хезмәт отряды-2018 конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5791 нче карары белән расланган 2017-2019 елларга муниципаль яшьләр программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенә Яр Чаллы шәһәрендә иң яхшы студентлар хезмәт отряды-2018 конкурсын (алга таба – конкурс) 2018 елның ноябрь-декабрендә оештыру һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурс үткәрү чыгымнарын финанслауны 2018 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлегендә каралган акчалар хисабына 30 000 сум (утыз мең сум) күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 28 ноябрендәге
7075 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә иң яхшы студентлар
хезмәт отряды-2018 конкурсы турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә 2018 елда Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы студентлар хезмәт отряды конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Әлеге нигезнамә конкурсны үткәрү срокларын, этапларын һәм катнашучыларга таләпләрне билгели.

3. Конкурсның максаты булып Яр Чаллы шәһәре территориясендә студентлар хезмәт отрядлары (алга таба – СХО) хәрәкәтенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү тора.

4. Конкурсны үткәрү бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәрендә отрядлар эшчәнлеген активлаштыру;

2) хезмәт отрядлары хәрәкәтен үстерү;

3) хезмәт отрядларының иң яхшы традицияләрен дәвам итү;

4) иң яхшы отрядларның эш тәҗрибәсен өйрәнү, гомумиләштерү һәм тарату;

5) студентлар отрядлары төзүдә белем бирү оешмаларының кызыксынуын арттыру;

6) хезмәт отрядларында эшне оештыру;

7) җәйге чорда яшьләрнең мәшгульлеген тәэмин итү.

5. Конкурс үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

2 бүлек. Конкурс этаплары

6. Конкурс 4 этапта үткәрелә:

1 этап – «Заявкалар кампаниясе»;

2 этап – «Спорт ул – тормыш!»;

3 этап – «Интеллект ул – көч!»;

4 этап – «Иҗат ул – уңышка юл!».

7. «Заявкалар кампаниясе» этабы. Конкурста катнашуга заявкалар оештыру комитетына 2018 елның 30 ноябренә кадәр срокта, әлеге нигезнамәнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча sto-chelny@mail.ru. электрон адресына җибәрелә. Оештыру комитетына

күрсәтелгән сроктан соң тапшырылган яки тиешенчә рәсмиләштерелмәгән мәгълүмат каралмый.

8. Заявканы карау өчен социаль челтәрләрдә СХО турында мәгълүмат куярга кирәк: отряд турында, вожатыйлар турында, теләсә нинди сурәтләү, техник чаралар турында (видеосәламләү, фотоколлаж, эссе, отряд турында җыр һәм башкалар). Социаль челтәрләргә мәгълүмат: #лучшийотрядчелнов, #РСОЧелны, #отрядычелнов, #молодежьчелнов, #отрядытатарстана, #РСО, #молодежьтатарстана хештеглары астында куела.

9. «Заявкалар кампаниясе» этабы кысаларында катнашучыларга түбәндәге чараларны оештырырга кирәк:

1) хәйрия акциясе;

2)Татарстан Республикасында СХО хәрәкәтенең 55 еллыгына багышланган видеоролик төшерергә;

3) СХО ветераннары белән очрашу үткәрергә;

4) портфолио әзерләргә.

10. Портфолио түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) әлеге карарга 2 нче кушымтадагы форма буенча СХО анкетасы;

2) СХО турында нигезнамә;

3) комиссар яки командир хисаплары;

4) СХО чараларының перспектив планы;

5) рекомендация хатлары, фикерләр (белем бирү оешмаларыннан, эш бирүчеләрдән, социаль партнерлардан һәм башкалардан);

6) дипломнар, рәхмәт хатлары, мактау грамоталары, сертификатлар;

7) иллюстрацияләр (фоторәсемнәр, газетадан кисеп алынган язмалар, видеоматериаллар һәм башкалар);

8) катнашучының казанышларын һәм җиңүләрен дәлилләгән башка документлар һәм материаллар.

11. «Заявкалар кампаниясе» этабында отрядлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) хезмәт дисциплинасы (прогуллар, гадәттән тыш хәлләр, штрафлар һәм башкалар булмау);

2) отрядның казанышлары (рәхмәтләр, премияләр, мактау билгеләре һәм башкалар);

3) социаль әһәмияткә ия чаралар оештыру (шефлык эше, өмәләр, агитация чаралары);

4) катнашучы оешма җитәкчелегенең фикере;

5) PR эше (отряд эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту);

6) отрядның социаль челтәрләрдә #лучшийотрядчелнов, #РСОЧелны, #отрядычелнов, #молодежьчелнов, #отрядытатарстана, #РСО, #молодежьтатарстана хештеглары белән катнашуын яктырту.

12. «Спорт ул – тормыш!» этабы – спорт эстафетасы. Отряд 10 кеше + җанатарлар белән катнаша. Отрядлар түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) ярдәм күрсәтүчеләр булу;

2) бердәм форма;

3) команданың исеме һәм девизы булу;

4) үтелгән спорт этапларының саны.

13. «Интеллект ул – көч!» этабы – интеллектуаль уен. Отряд 6 кеше + җанатарлар белән катнаша. Дөрес җаваплар саны җыелган баллар санына тигезләшә. Иң күп балл җыйган отряд җиңүче була.

14. «Иҗат ул – уңышка юл!» – иҗади фестиваль. Һәр команда түбәндәге юнәлешләр буенча иҗади номер әзерли: вокал, хореография, КВН, оригиналь жанр. Һәр юнәлеш биш баллы система буенча бәяләнә.

Йомгаклау этабы 2018 елның 12 декабрендә Яр Чаллы шәһәренең «Укучы һәм студент яшьләрне эшкә урнаштыру үзәге» МАУ да (Комаров урамы, 24 йорт) үтәчәк.

## 4 бүлек. Конкурс йомгаклары

15. Оештыру комитеты катнашучылар тарафыннан иң күп санда җыелган баллар, күпчелек тавыш буенча җиңүчеләрне билгели.

16. Конкурс җиңүчеләре дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәрендә иң яхшы
студентлар хезмәт отряды-2018
конкурсын оештыру һәм үткәрү
турында нигезнамәгә
1 нче кушымта

«Иң яхшы студентлар хезмәт отряды» конкурсында
катнашуга заявка

1. Хезмәт отрядының профиле ________________________________________
2. Белем бирү оешмасына яки иҗтимагый берләшмәгә караган булуы ______
_____________________________________________________________________
3. Отрядның исеме______________________________________________
4. Отряд командирының Ф.И.А.и. _____________________________________
5. Отряд комиссарының Ф.И.А.и._____________________________________
6. Отрядны төзү датасы_____________________________________________
7. Отрядтагы кешеләр саны_________________________________________
8. Отряд тарафыннан башкарыла торган төп эшләрнең исеме ______________
_____________________________________________________________________
9. Отрядның казанышлары (рәхмәтләре, премияләре, мактау билгеләре һәм башкалар) ______________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Заявка тутырган затның Ф.И.А.и., вазыйфасы____________________________
_____________________________________________________________________

Яр Чаллы шәһәрендә иң яхшы
студентлар хезмәт отряды-2018
конкурсын оештыру һәм үткәрү
турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

«___________________» студентлар хезмәт отряды
АНКЕТАСЫ

1. Студентлар хезмәт отрядының мәгълүмат картасы

| Т/с | Күрсәткечләр | Конкурста катнашучының мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1 | Студентлар хезмәт отрядының тулы исеме | |
| 2 | Студентлар хезмәт отрядын төзү датасы | |
| 3 | Студентлар хезмәт отряды базасы | |
| 4 | «Россия студентлар отрядлары» яшьләр гомумроссия иҗтимагый оешмасының төбәк бүлегендә (булганда) теркәлүе | |
| | | |
| 5 | Отряд җитәкчесе (командиры) | Ф.И.А.и. |
| | | Туу датасы |
| | | Туган урыны |
| | | Элемтә мәгълүматлары (телефон, социаль челтәрләргә сылтама, e-mail) |
| 6 | Отряд комиссары | Ф.И.А.и. |
| | | Туу датасы |
| | | Туган урыны |
| | | Элемтә мәгълүматлары (телефон, социаль челтәрләргә сылтама, e-mail) |
| 7 | Методист/отряд мастеры | Ф.И.А. и. |
| | | Туу датасы |
| | | Туган урыны |
| | | Элемтә мәгълүматлары (телефон, социаль челтәрләргә сылтама, e-mail) |
| 8 | Эш урынына барган отрядтагы кешеләр саны | 2016 – |
| | | 2017 – |
| | | 2018 – |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | 2018 елда отрядның эшләгән чоры | |
| 10 | «Интернет» челтәрендә урнаштырылган видеоролик/слайд шоуга (булганда) сылтама | |
| 11 | Отрядның барлык кешеләре эшләп алган акчаларның күләме | |
| 12 | Студентлар хезмәт отряды кешеләренең чараларда һәм проектларда катнашулары (катнашкан чараларны һәм отряд кешеләре санын күрсәтергә) | |
| 16 | Отрядның хәйрия һәм иреклеләр эшчәнлеге (катнашкан чараларны һәм отряд кешеләре санын күрсәтергә) | |
| 17 | Республика Штабының һәм отрядның үткәрелгән иҗади, иреклеләр һәм патриотик чараларының массакүләм мәгълүмат чараларында искә алынган саны (басылып чыккан материалларның сылтамасын күрсәтергә яки аны портфолиога теркәргә) | |

Мәгълүматларны командир ________________ / _____________________бирде

Анкета мәгълүматлары заявка бирүче оешма җитәкчесе тарафыннан раслана (югары белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесе, идарә /шәһәр яшьләре белән эшләү бүлеге башлыгы).

Дата
Имза

Башкарма комитетның
2018 елның 28 ноябрендәге
7075 нче карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә иң яхшы студентлар хезмәт отряды-2018 конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 2. | Хафизов Рәсим Рәхимҗан улы | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары, яшьләр белән эшләү бүлеге башлыгы |
| 3. | Вәлиев Рафаэль Илгизәр улы | «Укучы һәм студент яшьләрне эшкә урнаштыру үзәге» МАУ директоры |
| 4. | Николаева Надежда Григорьевна | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе яшьләр белән эшләү бүлегенең баш белгече |
| 5. | Шуганов Егор Владимирович | «Укучы һәм студент яшьләрне эшкә урнаштыру үзәге» МАУ директоры урынбасары |
| 6. | Иванов Василий Васильевич | Яр Чаллы шәһәре студентлар хезмәт отрядлары штабы командиры (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 28 ноябрендәге
7075 нче карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә иң яхшы студентлар отряды-2018 конкурсын үткәрүгә смета

| Учреждениенең исеме | Чыгымнарның исеме | Бәясе сум |
|---|---|---|
| «Укучы һәм студент яшьләрне эшкә урнаштыру үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе | Канцелярия товарлары | 4 400 |
| | Типография чыгымнары | 8 050 |
| | Кыйммәтле бүләкләр | 17 550 |
| барлыгы: | | 30 000 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова